ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2026 с.Старое Дрожжаное № 350

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Советлар Союзы Герое П.С. Юхвитов исемендәге Хорновар-Шигали урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ филиалы «Чепкас-Илмәт башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» эшчәнлеген туктатып тору турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Г.Ф. Хәлиулловның докладын исәпкә алып, башлангыч мәктәп яшендәге балалар булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Советлар Союзы Герое П.С. Юхвитов исемендәге Хорновар-Шигали урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Чепкас-Илмәт башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» эшчәнлеген 2027 елның 31 августына кадәр туктатып торырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының "Советлар Союзы Герое П.С. Юхвитов исемендәге Хорновар-Шигали урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры вазифаларын башкаручы:

2.1. Филиал эшчәнлеген туктату турындагы мәгълүматны халыкка җиткерергә.

2.2. Филиалның барлык штатлы хезмәткәрләрен әлеге карар белән үз вакытында таныштырырга.

2.3. Филиалда инвентаризация үткәрүне тәэмин итәргә.

2.4. Мебель һәм җиһазларның сакланышын тәэмин итәргә.

2.5. Филиал хезмәткәрләренең эшен гамәлдәге хезмәт законнары нигезендә эшчәнлеген туктатып тору чорында оештырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Г.Ф. Халиуллловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов